РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Егоркино ав. КАРАР

«10» ноябрь 2021 ел № 6

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 24 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Каравыл Тавы авылы Завод урамы буенча 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы Завод урамы буенча 1-7нче, Төзүчеләр урамы буенча 1-3нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2021 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта минутта Каравыл Тавы авылы Дала урамы буенча 21 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы Дала урамы буенча 1-37нче, 4-52нчы, Кузнецов урамы буенча 2-16нчы, 1-27нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2021 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта минутта Каравыл Тавы авылы Мичурин урамы 23нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы Мичурин урамы буенча №1-67нче, №2-62 йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2021 елның 24 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Каравыл Тавы авылы Мәктәп урамы буенча 31Б адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл

Тавы авылы  Мәктәп урамы  №5-77, №4-102  нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Халык җыенын үткәрү өчен Каравыл Тавы торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга :

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан  тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган  акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау»

« РИЗА»                                        «КАРШЫ».

8. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгының «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Карауль тавы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 05 декабрендәге 2 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга

9. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә)һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга,  Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Каравыл Тавы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы                                        А.И.Борисов